**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2026 елның 2 апреле** **33-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2021 елның 25 октябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 78-РС номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (надзоры) һәм муниципаль контроль турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ нче номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (надзоры) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июледәге 248-ФЗ нче номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2021 елның 25 октябрендәге «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 78-РС нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

3 пунктының 3.3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: Профилактика программасында күздә тотылган профилактика чаралары Контрольлек итүче орган тарафыннан мәҗбүри рәвештә үткәрелә. Контрольлек итүче орган профилактика программасында күздә тотылмаган профилактика чараларын да үткәрә ала. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда контрольлек итүче орган түбәндәге төрле профилактика чараларын уздыра:

1. мәгълүмат бирү;
2. консультация бирү;
3. кисәтү белдерү;

4. профилактика визиты.

Әлеге чаралар «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (надзоры) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ нче номерлы Федераль законда бәян ителгән таләпләрне исәпкә алып үткәрелә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Э.В. Хисмәтовага йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы –**

**Совет рәисе:** **И.Ф.Зарипов**